КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 4 июль г.Казань № 620

2022 елда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре, Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү, физик культура һәм спорт буенча муниципаль оешмалар, яшьләр сәясәте өлкәсендәге хезмәткәрләрне шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү буенча пилот проектын тормышка ашыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре, Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү, физик культура һәм спорт буенча муниципаль оешмалар, яшьләр сәясәте өлкәсендәге хезмәткәрләрне (алга таба – хезмәткәрләр) шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү буенча пилот проектын тормышка ашыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Бу карарга теркәлгән 2022 елда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре, Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү, физик культура һәм спорт буенча муниципаль оешмалар, яшьләр сәясәте өлкәсендәге хезмәткәрләрнең шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибен (алга таба – Шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибе) расларга.

3. Бу карар үз көченә кергән көннән 2022 елның 31 декабренә кадәр

түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла дип билгеләргә:

Татарстан Республикасының социаль яклау, социаль хезмәт күрсәтү, халыкны эш белән тәэмин итү, физик культура һәм спорт буенча дәүләт оешмалары, Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт оешмалары, Татарстан Республикасының социаль яклау, физик культура һәм спорт буенча муниципаль оешмалары, Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендә муниципаль оешмалар хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавын тәэмин итү өлешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре һәм Татарстан Республикасындагы муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2004 ел, 16 апрель, 184 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре һәм Татарстан Республикасындагы муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибе гамәле туктатып торыла;

пенсионер хезмәткәрләрне шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү Шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибе яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 14 февраль, 97 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибе нигезендә аларның сайлап алуы буенча гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына хезмәткәрләрне шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслауны «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2021 елның 25 ноябрендәге 86-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган акча чикләрендә гамәлгә ашырырга.

5. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

Татарстан Республикасы территориясендә шифаханә-курорт дәвалавын гамәлгә ашыручы һәм Россия Федерациясенең Курорт фонды буенча дәүләт реестрына кертелгән шифаханә-курорт оешмасында шифаханә-курорт дәвалавына юлламаны 2022 елда Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән түләү (өлешчә түләү) өчен сертификатлар бирү ярдәмендә хезмәткәрләрне шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү эшен оештырырга;

Шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибен Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, социаль хезмәт күрсәтү, физик культура һәм спорт, Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендә муниципаль оешмаларга җиткерергә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин